**КАРАР**

**27 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 3100 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Туембаш авылының Ленин урамындагы юлларны асфальтлау һәм вак таш салып ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Туембаш авылының Ленин урамындагы юлга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Туембаш авылы зиратын карап тоту һәм коймалау, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;
- Туембаш авылы урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Туембаш авылының су суырту манарасын буяу һәм ремонтлау, буяу өчен материал сатып алу;
- Туембаш авылында янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру;
- Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, юлларны кардан чистарту, җәен территорияне чабу, трактор өчен отвал, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу;
- Туембаш авылының Ленин урамына ясалма тигезсезлек, җәяүлеләр кичүе, юл билгеләре урнаштыру һәм җәяүлеләр кичүен яктырту, килешү буенча эш өчен түләү;
- территорияне төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 390 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 198 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы198 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 3400 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Туембаш авылының Ленин урамында вак таш һәм асфальт түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Туембаш авылы зиратын карап тоту һәм коймалау, территориясен төзекләндерү, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документлары;

- Туембаш авылы урамнарын яктыртуны карап тоту һәм урнаштыру, урамны яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары;

- Туембаш авылының сууткәргеч челтәрләрен, су суырту манараларын төзү, карап тоту һәм ремонтлау, су саклау зоналарын төзекләндерү, проект-смета документлары;

- Туембаш авылы чишмәләрен төзекләндерү, проект-смета документлары;

- Туембаш авылында янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, ремонтлау; проект-смета документлары;

- Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, трактор өчен отвал, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары;

- Туембаш авылының Ленин урамына ясалма тигезсезлек, җәяүлеләр кичүе төзү, урнаштыру һәм карап тоту, җәяүлеләр кичүен яктырту, проект-смета документлары;

- Туембаш авылының Ленин урамына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту, проект-смета документлары;

- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов